# Ак кыш

Яратам мин ап-ак төсне,
Бөтен дөнья ап-ак төсле.
Куяннар да ак тун кигән,
Каеннар да ак туннан.
Бүреккә дә, керфеккә дә,
Борынга да ак кунган.
Шундый якты, шундый нурлы –
Бөтен дөнья ак кына...
Ап-ак була беләшулай
Безнең туган як кына.

Роберт Миңнуллин

# КЫШКЫ ТАБЫШМАКЛАР

1) **Шома табанлы чана**
**Атсыз да алга чаба-**
**Җитез булса аяклар,**
**Кулда була таяклар.**
**Бар бер чана**
**Утырасы юк,**
**Бассаң-үзе чаба.**
**Нәрсә ул? *(Чаңгы)***

***

2) **Кышын тауда шуалар, җәен җыеп куялар.**
**Нәрсә ул? *(Чана)***

***

3) **Зең-зең килә,**
**Тимер тәкә тиң килә.**
**Берсен-берсе куа килә,**
**Тояклары шуа килә. *(Тимераяк*)**

***

4) **Ике агай тездән,**
**Калышмыйлар бездән. *(Итек*)**

***

5) **Колаклы ябалак кыштан саклый. (*Бүрек)***

***

6) **Бер ягы – кыр, бер ягы урман. *(Тун)***

***

7) **Биш агайга бер күлмәк. *(Бияләй)***

***

8) **Бер агачта биш тармак,**
**Тармагы саен бармак. (*Пирчәткә*)**

## ТАТАР ХАЛКЫ ТАБИГАТЬТӘГЕ ҮЗГӘРЕШЛӘРГӘ ЭЛЕК-ЭЛЕКТӘН ИГЪТИБАР ИТКӘН ҺӘМ АЛДАГЫ КӨН, АЙ ҺӘМ, ХӘТТА, ЕЛДА ҺАВА ТОРЫШЫ НИНДИ БУЛАЧАГЫН АЛДАН СЫНЫЙ ТОРГАН БУЛГАН...

**– Болытлар түбәннән килсә, каты суыкны көт.**

**– Кыш көне болытлар юлланып торса, җәй җылы булыр.**

**– Кышның төньяк бураннары ашлык җыйганда яңгыр китерер.**

**– Көн озая башлагач, гыйнвар башында, бәс төшсә, җәй ашлык чәчкәндә чык булыр.**

**– Гыйнварның унында бәс төшсә, җәй яңгырлы килер.**

**– Гыйнварның егерме дүртендә булса аяз, бик нәфис килер яз.**

**– Кышын бәс, томан булса, җәй иген уңа.**

**– Кыш көне яңгыр яуса, икмәк булыр.**

**– Кыш сыкылы булса, җәй алмалы була.**

**– Кыш томан булса, җәй юкәдә бал була.**

**– Әгәр кар вак кына бөртекле, сирәк кенә төшкәләсә, бик озак суык булыр.**

**– Кыш кар күп булса, җәй яңгырлы булыр.**

**– Гыйнвар унында бәс тотса, җәй яңгырлы килә.**

**– Әгәр елга суы боз өстенә чыкса, көн җылытыр.**

**– Тоз юеш булса, кыш көне җепшек була.**

**– Морҗадан чыккан төтен туры булып өскә менсә, көн аяза, суыта. Әгәр төтен җиргә ятса, көн җылыта.**

**– Утын сызгырса, көн суытыр.**

**– Тау башларында кар күп булса, җиләк күп булыр.**

# Кыш

Бөтен дөньяны ап-ак кар каплады. Табигать җем-җем итеп торган яңа матур күлмәген киде. Агачлар да җылы мамык шәлләрен ябынды. Елгалар, күлләр күзгә кебек шома боз белән капланды. Урман-кырлар өстендә тантаналы тынлык. Кыш көне көннәр кыска, салкын. Без, балалар, чаңгы-чанада, тимераякта шуабыз. Безне көннең салкынлыгы да куркытмый. Безнең тавыштан урам шау-гөр килеп тора. Кыш — иң матур ел фасылларының берсе. Туган ягыбызның кышкы табигате бигрәк матур



